Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Мәмәт авылы башкарма комитеты

# КАРАР

№1 20 февраль 2021 ел

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында

«Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күму эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 нчы номерлы карары нигезендә, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәрендәге идарәсе (районара) Дәүләт учреждениесенең 2021 елның 19 гыйнварындагы БЛ-08-01-12/242 номерлы мөрәҗәгате нигезендә

Мәмәт авылы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2021 елның 1 февраленнән 6 424,98 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә, 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә.

2. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын билгеләү турында» гы Мәмәт авылы башкарма комитетының 2020 елның 22 апрелендәге 1 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карарны Әлмәт районы, Мәмәт авылы, Совет урамы, 1 нче йорт, Чупай авылы Совет урамы, 43А йорты, Сәмәрканд бистәсе, Үзәк урамы, 1 нче йорт территоиясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2021 елның 01 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз артымда калдырам.

Мәмәт авылы
башкарма комитеты җитәкчесе И.М.Зөбәерова

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Мәмәт авылы башкарма
комитетының 2021 елның
20 февралендәге 1 нче
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Мәмәт авылы җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге
нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 91,02 |
| 2 | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3689,02 |
| 3 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 573,12 |
| 4 | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2071,82 |
| Барлыгы | | 6424,98 |

Мәмәт авылы
башкарма комитеты җитәкчесе И.М.Зөбәерова

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Мәмәт авылы башкарма
комитетының 2021 елның
20 февралендәге 1 нче
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Мәмәт авылы җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге
нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 91,02 |
| 2 | Үлгән кешенең гәүдәсен төрү | 2162,78 |
| 3 | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1526,96 |
| 4 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 573,12 |
| 5 | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2071,81 |
| Барлыгы | | 6424,98 |

Мәмәт авылы
башкарма комитеты җитәкчесе И.М.Зөбәерова